Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Чыты авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР

12.10.2021 ел № 20

«Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Чыты авыл җирлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Чыты авыл җирлеге территориясендә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2016 елның 13 апрелендәге 9 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында (2021 елның 3 февралендәге 4 номерлы үзгәрешләр белән)

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Чыты авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Чыты авыл җирлеге территориясендә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Чыты авыл җирлеге башкарма комитеты карары (2021 елның 3 февралендәге 4 номерлы үзгәрешләр белән) белән расланган адресларны бирү, үзгәртү һәм бетерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.5 пунктының 2 - 10 абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Регламентта дәүләт адреслы реестрын алып баруга һәм федераль мәгълүмат адреслы системасын эксплуатацияләүгә бәйле кулланыла торган төшенчәләр Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Федераль мәгълүмат адреслы системасы турында һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 19 ноябрендәге 1221 номерлы «Адреслар бирү, үзгәртү һәм бетерү кагыйдәләрен раслау турында» Федераль закон белән төгәл киңәшләшүдә кулланыла.»;

1.2. 1.5 пунктының 11 - 17 абзацларын 3 - 9 абзацлар дип санарга;

1.3. 2.6.1 пунктының 4 - 7 пунктчаларында «Башкарма комитет» сүзен «муниципаль районның җирле үзидарә органы яисә килешү нигезендә Башкарма комитет» сүзләренә алмаштырырга;

1.4. 2.6.1 пунктының 8 пунктчасында «Башкарма комитет» сүзен «төзелгән килешү нигезендә муниципаль районның Башкарма комитеты яисә җирле үзидарә органы» сүзләренә алмаштырырга;

1.5 2.6.4 пунктында «Башкарма комитеты структура бүлекчәсе» сүзләрен «муниципаль районның җирле үзидарә органнары, Башкарма комитет белән» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында http://www.pestreci.tatarstan.ru һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы» http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткергәннән) соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Чыты авыл җирлеге башлыгы С.Ә.Фәйзрахманов